**Татарстан Республикасы Ютазы район Советы**

**Карар №48**

III чакырылыш чираттан тыш утырышы  Урыссу штб  2019 елның 9 декабре

Ютазы муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 нче маддәсе нигезендә Ютазы муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Ютазы муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге Карар нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021һәм 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Р.Г. Мөхәммәтовага йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы Башлыгы урынбасары
З. М. Әгълиева

Ютазы район Советының 09.12.2019
ел №48 карары белән расланды

## Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Ютазы муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү Кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләр (алга таба – субвенцияләр, җирлекләр) бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Субвенцияләр Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында җирлек бюджетларына бирелә.

3. Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетына бирелә торган субвенция тора.

4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче булып Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тора.

5. Җирлек бюджетына субвенция күләме «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпләү Методикасы нигезендә билгеләнә.

6. Муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләрне бүлү Ютазы муниципаль районы Советының тиешле финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы карары белән раслана.

7. Субвенцияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Башкарма комитетка билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

8. Гражданлык хәле актлары язмаларын төзү һәм башка юридик яктан әһәмиятле гамәлләр кылу өлешендә субвенцияләр түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыруга бирелә:

хезмәткә түләү һәм хезмәт өчен түләүне хисаплау;
командировка чыгымнары;
элемтә хезмәтләре;
транспорт хезмәтләре;

коммуналь хезмәтләр;
мөлкәтне файдалану буенча хезмәтләр;
мөлкәтне карап тоту буенча эшләр, хезмәтләр;
башка эшләр, хезмәтләр;
төп чаралар сатып алу;
матди запаслар сатып алу;
салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр түләү;
башка чыгымнар.

9. Субвенцияләрне тоту Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча Идарәсенең территориаль органнарының (алга таба – Казначылык) шәхси счетлары аша башкарыла.

10. Башкарма комитет казначылыктан финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен чыгым расписаниесен алганнан соң җиде эш көне эчендә Казначылыкка субвенцияләр исәбеннән җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына гариза бирә.

11. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары, хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, финанс тәэминаты чыганагы субвенция булган Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле җирлекләрнең бюджетлары чыгымнары турындагы хисапны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы белән килешү буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча җирлекләрнең Башкарма комитетына тапшыралар.

12. Башкарма комитетка бирелә торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты керемenә күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субвенцияләрнең калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, муниципаль район бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тотуны законнар нигезендә Башкарма комитет һәм муниципаль районның финанс органы башкара.